**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

РАСПОРЯЖЕНИЕ | БОЕРЫК

№ 194-р | 30 март 2015 ел

Нурлат муниципаль районы территориясендә «Татарстанның чиста урманнары» акциясен үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 26.03.2015 ел, №494-р күрсәтмәсен үтәү һәм Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан урманнарда санитар-экологик хәлне уңай итү максатларында:

1. 2014 елның 1 апреленнән 1 июненә кадәр һәм 1 сентябреннән 1 ноябренә кадәр Нурлат муниципаль районы территориясендә «Татарстанның чиста урманнары» республикакүләм табигатьне саклау акциясен (алга таба-икеайлык) игълан итәргә.

2. «Нурлат урманчылыгы» ДБУ һәм «Нурлатлес» ДКУ җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- авыл җирлекләре һәм урман кишәрлекләреннән файдаланучылар белән берлектә урманнарны чүп-чардан һәм пычранудан даими (сроксыз) файдалануга, арендага, түләүсез сроклы файдалануга бирелгән;
- урман фонды җирләрендә урнаштырылган кече архитектура формаларын ремонтлау һәм төзекләндерү;
- «Татмедиа» ААҖ филиаллары: «Дуслык» газетасы редакциясе һәм «Нурлат» телерадиокомпаниясе белән берлектә акцияне массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

3. Предприятиеләргә, оешмаларга, авыл җирлекләренә акциядә актив катнашырга һәм урманнарны чүп-чардан һәм пычранудан чистарту буенча коллективлар эшен оештырырга тәкъдим итәргә.

3. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге яшьләрне иҗтимагый берләшмәләрне һәм оешмаларны акциядә катнашуга җәлеп итү эшен оештырырга.

4. Транспорт предприятиеләренә һәм оешмаларына, авыл хуҗалыгы формированиеләренә акциядә катнашучыларны каты калдыклар һәм чүп-чарны каты көнкүреш калдыклары полигоннарына чыгару өчен кирәкле транспорт чаралары белән тәэмин итүдә ярдәм итәргә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Ә.К. Габдуллин